**МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**30.03.2020** г. Казань **№ 566**

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының “Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләре сугышлар ветераннары өчен госпитальләрендә гражданнарның льготалы категорияләренә медицина ярдәмен оештыру турында” 2019 елның 12 февраленнән 251 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Ветераннар турында» 1995 елның 12 гыйнварыннан 5-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче сугышларда катнашучыларга, инвалидларга һәм аларга льготалы категориягә тиңләштерелгән Россия Федерациясенең башка гражданнарына медицина ярдәмен оештыруны камилләштерү максатларында боерам:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының “Казан һәм Яр Чаллы шәһәрләре сугышлар ветераннары өчен госпитальләрендә гражданнарның льготалы категорияләренә медицина ярдәмен оештыру турында” 2019 елның 12 февралендәге 251 номерлы боерыгына (алга таба – боерык) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 нче пунктта “С.А.Осипов” сүзен “А.Р.Абашев” сүзен алмаштырырга;

боерыкка 1 номерлы нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

боерыкка 4 номерлы нигезләмәгә 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме күрсәтүне таләп итә торган авырулар.»;

боерыкка №5 нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

боерыкка №6 нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Министр М.Н.Садыйков

2019 елның 12 февраленнән № 251
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгына
№ 1 Кушымта
(Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы редакциясендә
30.03.2020 № 566)

Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе гражданнарына түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең Дәүләт гарантияләре программасы кысаларында Казан шәһ. “Сугышлар ветераннары өчен госпиталь” ДАССУдә һәм Яр Чаллы шәһ. “Сугышлар ветераннары өчен госпиталь” ДАССУдә медицина ярдәме алуга хокуклары булган Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының льготалы категорияләре

Исемлеге

| Категория исеме | Категориягә кертү өчен нигез |
|---|---|
| 1. Бөек Ватан сугышы ветераннары: | |
| 1) Бөек Ватан сугышында катнашучылар:<br>а) гражданнар сугышы чорында, Бөек Ватан сугышы чорында яки Ватанны саклау буенча башка хәрби операцияләр чорында хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частьләрдә, штабларда һәм учреждениеләрдә хәрби хезмәт үткән (хәрби частьләрдә тәрбияләнүчеләр һәм юнгаларны кертеп) яки вакытлыча анда булган хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска (отставкага) җибәрелгәннәр, шулай ук гражданнар сугышы яки Бөек Ватан сугышы чорында СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эш иткән партизаннар һәм яшерен оешмалар әгъзалары;<br>б) оборонасында катнашу хәрәкәттәге армия хәрби частьләрнең хәрби хезмәткәрләре өчен билгеләнгән льготалы шартларда пенсияләр билгеләү өчен тиешле елллар эшләгәнгә исәпләнә торган шәһәрләрдә Бөек Ватан сугышы чорында хәрби хезмәт үткән хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска (отставкага) җибәрелгәннәр, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының | 1995 елның 12 гыйнварыннан № 5-ФЗ «Ветераннар турында», 2 статьясы |

| | |
|---|---|
| рядовой һәм җитәкче составы шәхесләре;<br>в) Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьләрдә, штабларда һәм учреждениеләрдә штат вазыйфалары биләгән яисә әлеге чорда оборонасында катнашу хәрәкәттәге армия хәрби частьләренең хәрби хезмәткәрләре өчен билгеләнгән льготалы шартларда пенсияләр билгеләү өчен тиешле еллар эшләгәнгә исәпләнә торган шәһәрләрдә булган армиянең һәм флотның, гаскәрләренең һәм эчке эшләр органнарының, дәүләт иминлеге органнарының ялланган составы шәхесләре;<br>г) Бөек Ватан сугышы чорында гамәлдәге армия составына кергән хәрби частьләрдә, дошманның тылында яки башка дәүләтләр территорияләрендә махсус йөкләмәләр башкарган разведка, контрразведка хезмәткәрләре;<br>д) Бөек Ватан сугышы чорында Кызыл Армия сафларындагы шәхесләр сыйфатында күчерелгән һәм хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә яки хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә армия һәм флот мәнфәгатьләрендә йөкләмәләр үтәгән предприятиеләр һәм хәрби объектлар, халык комиссариатлары, ведомстволар хезмәткәрләре, шулай ук Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге армиягә командировкага җибәрелгән учреждениеләр һәм оешмалар (шул санда мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре һәм оешмалары) хезмәткәрләре, үзәк газеталар, журналлар, ТАСС, Совинформбюро һәм радио корреспондентлары, Документаль фильмнар (кинохроника) үзәк студиясе кинооператорлары;<br>е) Бөек Ватан сугышы чорында дошман десантларына каршы көрәш буенча хәрби операцияләрдә һәм хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьләр белән берлектә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан, шулай ук 1944 елның 1 гыйнварыннан башлап 1951 елның 31 декабренә кадәрге чорда Украина, Белоруссия, Литва, Латвия һәм Эстония территорияләрендә милли подпольены бетерү буенча хәрби операцияләрдә катнашкан хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) җибәрелгәннәр, эчке эшләр | |

| | |
|---|---|
| органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовой һәм житәкче составы шәхесләре, сугышчылар һәм истребительләр батальоннарының, взводларның һәм халыкны яклау отрядларының командалы составы. Бөек Ватан сугышы чорында хәрәкәттәге флот составына кермәгән бүлекчәләрдә хәрби траллау операцияләрендә катнашкан, шулай ук 1941 елның 22 июненнән башлап 1945 елның 9 маена кадәрге чорда СССРның Осоавиахим оешмалары һәм жирле хакимият органнары тарафыннан территорияләрне һәм объектларны миналардан арындыру, сугыш кирәк-яраклары һәм хәрби техника жыю өчен жәлеп ителгән шәхесләр;<br>ж) партизан отрядлары, яшерен төркемнәр, Бөек Ватан сугышы чорындагы фашистларга каршы башка формированиеләр составында башка дәүләтләр территорияләрендә фашист Германиясенә һәм аның союздашларына каршы хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан шәхесләр;<br>з) 1941 елның 22 июненнән башлап 1945 елның 3 сентябренә кадәрге чорда кимендә алты ай хәрәкәттәге армия составына кермәгән хәрби частьләрдә, учреждениеләрдә, хәрби уку йортларында хәрби хезмәт үткән хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска (отставкага) жибәрелгәннәр; күрсәтелгән чорда хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән хәрби хезмәткәрләр;<br>и) “Ленинград оборонасы өчен” медале белән бүләкләнгән шәхесләр, 1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы чорында хәрби хәрәкәтләргә бәйле яралану, контузия алу яки имгәнү сәбәпле балачактан инвалид булганнар;<br>2) хәрәкәттәге фронтларның тыл чикләрендә, хәрәкәттәге флотларның операция зоналары чикләрендә, тимер юллар һәм автомобиль юлларының фронт буендагы участокларында һава Һөжүменә каршы оборона объектларында, жирле һава һөжүменә каршы оборонада, оборона корылмалары, хәрби-диңгез базалары, аэродромнар һәм башка хәрби объектлар төзелешендә эшләгән шәхесләр; Бөек Ватан сугышы башланганда башка дәүләтләр портларында иректән мәхрүм ителгән | |

| | |
|---|---|
| транспорт флоты суднолары экипажлары әгъзалары;<br>3) “Блокадалы Ленинградта яшәүчегә” билгесе белән бүләкләнгән;<br>4) СССРның вакытлыча оккупацияләнгән территорияләрендә эшләү чорын кертмичә, 1941 елның 22 июненнән 1945 елның 9 маена кадәрге чорда кимендә алты ай тылда эшләгән шәхесләр; Бөек Ватан сугышы чорында фидакарь хезмәт өчен СССР орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән шәхесләр | |
| 2. Хәрби хәрәкәтләр ветераннары:<br>1) СССР дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары тарафыннан башка дәүләтләргә җибәрелгән һәм бу дәүләтләрдә хезмәт бурычларын үтәгәндә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан, шулай ук Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә Россия Федерациясе территорияләрендә хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска (отставкага) җибәрелгәннәр, хәрби җыеннарга чакырылган хәрби бурычлар, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовой һәм җитәкче составы шәхесләре, әлеге органнар хезмәткәрләре, СССР Оборона министрлыгы хезмәткәрләре һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгы хезмәткәрләре, җинаять-башкарма системасы учреждениеләре һәм органнары;<br>2) 1945 елның 10 маеннан башлап 1951 елның 31 декабренә кадәрге чорда СССР территориясендә һәм башка дәүләтләр территорияләрендә территорияләрне һәм объектларны миналардан арындыру буенча хөкүмәтнең хәрби заданиеләрен үтәгәндә операцияләрдә, шул санда 1945 елнаң 10 маеннан башлап 1957 елның 31 декабренә кадәрге чорда хәрби траллау буенча операцияләрдә катнашкан хәрби хезмәткәрләр, шул исәптән запаска (отставкага) җибәрелгәннәр, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовой һәм җитәкче составы шәхесләре;<br>2.1) Дагыстан Республикасы башкарма хакимияте | 1995 елның 12 гыйнварыннан № 5-ФЗ «Ветераннар турында», 3статьясы;<br>«Россия Федерациясен мәҗбүри үтәү органнарында хезмәт итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 1 октябрендәге 328-ФЗ номерлы Федераль закон, 98 статья;<br>«Ветераннар турында «Федераль законның 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 августындагы 320-ФЗ номерлы Федераль закон, 1 статья |

| | |
|---|---|
| органнары карарлары нигезендә Дагыстан Республикасы территориясендә 1999 елның августыннан сентябренә кадәрге чорда контртеррористик операцияләрдә Дагыстан Республикасы үз-үзеңне яклау отрядлары составында хәрби хәрәкәттә катнашкан шәхесләр;<br>3) Әфгәнстанда сугыш хәрәкәтләре алып барылган чорда йөкләр китерү өчен Әфгәнстанга җибәрелгән автомобиль батальоннарының хәрби хезмәткәрләре;<br>4) Әфгәнстанда сугыш хәрәкәтләре алып барылган чорда Әфгәнстанга СССР территориясеннән хәрби заданиеләргә очышлар ясаган очу составының хәрби хезмәткәрләре;<br>5) башка дәүләтләр территорияләрендә булган һәм анда хәрби хәрәкәтләр барган чорда СССР Кораллы Көчләрнең һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләрнең хәрби частьләренә хезмәт күрсәткән, моңа бәйле рәвештә яраланулар, контузияләр яки имгәнүләр алган яисә күрсәтелгән хәрби хәрәкәтләрне тәэмин итүдә катнашкан өчен СССР яисә Россия Федерациясе орденнары яисә медальләре белән бүләкләнгән шәхесләр (Әфгәнстанда, анда сугыш хәрәкәтләре алып барылган чорда, очышлар башкарган гражданнар авиациясе һава судноларының очкыч экипажлары әгъзаларын да кертеп);<br>6) 1979 елның декабреннән башлап 1989 елның декабренә кадәрге чорда Әфганстанга эшкә җибәрелгән, юнәлткәндә билгеләнгән срокны эшләп чыккан яки нигезле сәбәпләр буенча вакытыннан алда кире командировкаланган шәхесләр;<br>7) 2015 елның 30 сентябреннән башлап Сирия Гарәп Республикасы территориясендә махсус бурычларны үтәүне тәэмин итү өчен эшкә җибәрелгән, командировкаланган шәхесләр | |
| Бөек Ватан сугышы инвалидлары һәм хәрби хәрәкәтләр инвалидлары:<br>1) хәрәкәттәге армия составына керүче хәрби частҗләрдә, штабларда һәм учреждениеләрдә хәрби хезмәт үткән (хәрби частьләрдә тәрбияләнүчеләр һәм юнгаларны кертеп) яки вакытлыча анда булган хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска(отставкага) | 1995 елның 12 гыйнварыннан № 5-ФЗ «Ветераннар турында», 4статьясы «Россия Федерациясен мәҗбүри үтәү органнарында хезмәт итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон |

| | |
|---|---|
| җибәрелгәннәр, гражданнар сугышы чорында яки Бөек Ватан сугышы чорында СССРның вакытылчы оккупацияләнгән территорияләрендә эш иткән партизаннар, яшерен оешмалар әгъзалары, хәрби хәрәкәтләр барган урыннарда эшләгән, гражданнар сугышы чорында яки Бөек Ватан сугышы чорында хәрби хәрәкәтләр барган урыннарда яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган һәм пенсия белән тәэмин итү ягыннан хәрәкәттәге армия составына кергән хәрби частьләрнең хәрби хезмәткәрләренә тигезләштерелгән эшчеләр һәм хезмәткәрләр;<br>2) Ватанны саклаганда яки бу Федераль законда күрсәтелгән чорларда фронтта, хәрби хәрәкәтләр барган районнарда хәрби хезмәт бурычларын үтәгәндә яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган хәрби хезмәткәрләр;<br>3) хәрби хәрәкәтләрбарган районнарда хәрби бурычларын үтәгәндә яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган эчке эшләр органнарының, милли гвардия гаскәрләренең, Дәүләт янгынга каршы хезмәтенең, җинаять-башкарма системасы органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовой һәм җитәкче составына кергән шәхесләр;<br>4) 1941 елның 22 июненнән башлап 1951 елның 31 декабренә кадәрге чорда хәрби заданиеләрне үтәгәндә, шулай ук СССР Хөкүмәте карарлары нигезендә 1941 елның 22 июненнән башлап 1957 елның 31 декабренә кадәрге чорда СССР территориясендә һәм башка дәүләтләр территорияләрендә территорияләрне һәм объектларны миналардан арындырганда, хәрби траллау буенча операцияләрне кертеп, алган яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган хәрби хезмәткәрләр, эчке эшләр органнарының һәм дәүләт иминлеге органнарының рядовой һәм җитәкче составы шәхесләре, сугышчылар һәм истребительләр батальоннарының, взводларның һәм халыкны яклау отрядларының командалы составы;<br>5) 1944 елның февраленнән башлап 1951 елның декабренә кадәрге чорда СССР Осоавиахим | актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 1 октябрендәге 328-ФЗ номерлы Федераль закон, 98 статья;<br>«Ветераннар турында «Федераль законның 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 2 августындагы 320-ФЗ номерлы Федераль закон, 1 статья |

| | |
|---|---|
| оешмалары һәм җирле хакимият органнары тарафыннан сугыш кирәк-яракларын һәм хәрби техника җыюга, территорияләрне һәм объектларны миналардан арылындыруга җәлеп ителеп, шушы чорда яралану, контузияләнү яки имгәнү аркасында инвалид калган шәхесләр;<br>6) башка дәүләтләр территорияләрендәге СССР Кораллы Көчләренең һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренең хәрәкәттәге хәрби частьләренә хезмәт күрсәткән һәм бу дәүләтләрдә хәрби хәрәкәтләр алып барылган чорда яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган шәхесләр;<br>7) Дагыстан Республикасы башкарма хакимияте органнары карарлары нигезендә Дагыстан Республикасы территориясендә 1999 елның августыннан сентябренә кадәрге чорда контртеррористик операцияләрдә Дагыстан Республикасы үз-үзеңне яклау отрядлары составында хәрби хәрәкәттә катнашып, моңа бәйле рәвештә инвалид булган һәм күрсәтелгән чорда Дагыстан Республикасы үз-үзеңне яклау отрядлары составында яралану, контузияләнү яки имгәнү алу аркасында инвалид булуын раслаган Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хәрби хәрәкәт ветераны таныклыгын алган шәхесләр | |
| 4. Хәрби хезмәт ветераннары (хәрби хезмәткәрләр, шул санда запаска (отставкага) җибәрелгәннәр):<br>1) проходящие (проходившие) военную службу в Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, башка гаскәрләрдә, хәрби формированиеләрдә һәм Россия Федерациясе законнары белән хәрби хезмәт каралган органнарда, СССР Кораллы Көчләрендә хезмәт итүче (хезмәт иткән), Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге Уставы нигезендә төзелгән Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенң катнашучылары – дәүләтләрнең Берләшкән Кораллы Көчләрендә, яисә Кырым Республикасын Россия Федерациясенә кабул иткән көннән һәм Россия Федерациясе составында яңа субъектлар – Кырым Республикасы һәм федераль әһәмияткә ия Севастополь шәһәре | 1995 елның 12 гыйнварыннан № 5-ФЗ «Ветераннар турында», 5 статьясы;<br>«Ветераннар турында «Федераль законның 5 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 18 февралендәге 19-ФЗ номерлы Федераль закон, 1 статья |

| | |
|---|---|
| барлыкка килгәннән соң Кырым Автоном Республикасында һәсм Севастополь шәһәрендә даими яшәп, Кырым Автономияле Республикасы һәм Севастополь шәһәре территорияләрендә урнашкан частьларда һәм Украина Хәрби Көчләре оемашларында, хәрби формировантеләрдә һәм Украина законнары белән хәрби хезмәт каралган органнарда хәрби хезмәт үткән, СССР яки Россия Федерациясенең орденнары яки медальләре белән бүләкләнгән, яисә мактаулы исемнәренә лаек булган, яисә Россия Федерациясе Президентының Мактаулы грамоталары белән бүләкләнгән яки Россия Федерациясе Президентының Рәхмәтенә лаек булган, яисә Россия Федерациясе Кораллы Көчләр, Россия Федерациясе законнары белән хәрби хезмәт каралган башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнарның ведомство аерымлык билгеләре белән бүләкләнгәннәр, хәрби хезмәткәрләрнең гомуми хәрби хезмәт озынлыгы 20 ел һәм аннан да күбрәк булган очракта;<br>2) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә, Россия Федерациясе законнары белән хәрби хезмәт каралган башка гаскәрләрдә, хәрби формированиеләрдә һәм органнарда, СССР Кораллы Көчләрдә хәрби хезмәт итүче (иткән), Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлеге Уставы нигезендә төзелгән Бәйсез Дәүләтләр Бердәмлегенең катнашучылары – Дәүләтләрнең Берләшкән Кораллы Көчләренең хәрби хезмәткәрләре, шулай ук хәрби хезмәт бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә алган яралану, контузияләнү, имгәнү яки чирләү аркасында инвалид калган хезмәткәрләр | |
| 5. Һәлак булган (вафат булган) сугыш инвалидларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның, хәрби хәрәкәтләр ветераннарының тәрбиясендә булган һәм Россия Федерациясе Пенсия законнары нигезендә туендыручысын югалту очрагы буенча (аны алу хокукына ия) пенсия алучы гаилә әгъзалары | 1995 елның 12 гыйнварыннан № 5-ФЗ «Ветераннар турында», 21статьясы; |
| 6. “Японияне җиңү өчен” медале белән бүләкләнгән шәхесләр:<br>а) 1 Ерак Көнчыгыш, 2 Ерак Көнчыгыш һәм Байкал | 1945 елның 30 сентябреннән “Японияне җиңү өчен” медален раслау турында” |

| | |
|---|---|
| арты фронтларының, Тын океан флотының һәм Амур елгасы флотилиясенең гаскәрләре составында Япония империалистларына каршы хәрби хәрәкәтләрдә турыдан-туры катнашкан Кызыл армия, Хәрби-Диңгез Флоты һәм НКВД частҗләренең һәм кушылмаларының барлык хәрби хезмәткәрләре һәм ялланган штат составының шәхесләре;<br>б) Ерак Көнчыгышта совет гаскәрләренең хәрби хәрәкәтләрен тәэмин итүдә катнашкан НКО, НКВМФ һәм НКВД үзәк идарәләренең хәрби хезмәткәрләре | СССР Югары Советы Президиумы Указы |
| 7. “1941 – 1945 елларның Бөек Ватан сугышында Германияне җиңү өчен” медале белән бүләкләнгән шәхесләр<br>а) Кызыл Армия, Хәрби-Диңгез Флоты һәм НКВД гаскәрләре сафларында Ватан сугышы фронтларында катнашкан яки хәрби округларда үз эшләре белән җиңүне тәэмин иткән хәрби хезмәткәрләр һәм ялланган штат составының шәхесләре;<br>б) Бөек Ватан сугышы чорында гамәлдәге Кызыл Армия, Хәрби-Дингез Флоты һәм НКВД гаскәрләренең сафларында хезмәт иткән, әмма алардан яралану, авырулар һәм имгәнү буенча киткән, шулай ук дәүләт һәм партия оешмалары карары буенча армиядән читтә булган башка эшкә күчерелгән хәрби хезмәткәрләр һәм ялланган штат составының шәхесләре | 1945 елның 9 маеннан “1941-1945 елларның Бөек Ватан сугышында Германияне җиңү өчен” медален раслау турында” СССР Югары Советы Президиумы Указы |
| 8. Икенче бөтендөнья сугышы чорында фашистлар һәм аларның союзниклары тарафыннан корылган концлагерьләр, гетто һәм башка мәҗбүри тоту урыннарының балигъ булмаган тоткыннары | 2004 елның 22 августыннан №122-ФЗ “Россия Федерациясе” субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында” һәм “Россия Федерациясендә җирле |

| | |
|---|---|
| | үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” федераль законнары каҗбул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актлары үз көчләрен югалткан дип тану турында” Федераль законы, 154 статьясының 8 өлеше |
| 9. Акланган шәхесләр һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган шәхесләр | 1991 елның 18 октябреннән № 1761-1 «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында» Россия Федерациясе законы |
| 10. Советлар Союзы Герое, Россия Федерациясе Герое исемнәренә лаек булган яисә Дан орденының тулы кавалерлары булган гражданнар, Геройларның һәм Дан орденының тулы кавалерларының гаилә әгъзалары (тол калган хатыннары (тол калган ирләре), ата-аналары, 18 яшькә кадәрге балалары, 18 яшьтән өлкәнрәк инвалид булган балалары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларда көндезге формада белем алучы 23 яшькә кадәрге балалары), Геройларның һәм Дан орденының тулы кавалерларының вафат булу (һәлак булу) датасына карамастан | 1993 елның 15 гыйнварыннан №4301-1 «Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» Россия Федерациясе Законы |
| 11. Социалистик хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе хезмәт Геройлары, Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройларының яисә Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларының кабаттан никахка кермәгән тол калган хатыннары (тол калган ирләре) (Социалистик Хезмәт Героеның яисә Хезмәт Даны орденының тулы кавалерының вафат булу (һәлак булу) датасына карамастан) | 1997 елның 9 гыйнварыннан №5-ФЗ «Социалистик Хезмәт Геройларына, Россия Федерациясе Хезмәт Геройларына һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерларына социаль гарантияләр бирү турында» Федераль закон |
| 12. Аеруча куркыныч бүлекчәләр гражданнары | 1992 елның 11 декабреннән № 958 «Аерым куркыныч |

| | |
|---|---|
| | янаган бүлекчәләрдән гражданнарны социаль яклауны тәэмин итү чаралары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәте карары |
| 13.Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнары | 1991 елның 15 маеннан №1244-1 «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарны социаль яклау турында» Россия Федерациясе Законы |
| 14. 1957 елда “Маяк” җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклары эләгү аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнары | 1998 елның 26 ноябреннән №175-ФЗ «1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендә авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнарын социаль яклау ташлау турында» Федераль законы |
| 15. Җидепулат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән Россия Федерациясе гражданнары | 2002 елның 10 гыйнварыннан № 2-ФЗ «Җидепулат полигонында атом-төш сынаулары аркасында радиация йогынтысына дучар ителгән гражданнарга социаль гарантияләр турында» Федераль законы |

2019 елның 12 февраленнән № 251
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгына
№ 5 Кушымта
(Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы редакциясендә
30.03.2020 № 566)

Казан шәһ. "Сугышлар ветераннары өчен госпиталь" ДАССУдә консультатив кабул итүгә һәм планлы стационар дәвалауга льготалы категорияләр гражданнарын җибәргәндә медицина оешмаларының үзара эшчәнлек тәртибе

1. Казан шәһ. "Сугышлар ветераннары өчен госпиталь" ДАССУдә (алга таба – Госпиталь (Казан шәһ.) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының льготалы категорияләренә (алга таба – ветераннар, ветеран) сырхауханә (амбулатор һәм консультатив) һәм тәүлек буе эшли торган стационар медицина ярдәме күрсәтелә.

2. Ветераннарны госпитальнең (Казан шәһ.) сырхауханә бүлегенә консультатив кабул итүгә җибәрүче медицина оешмасы тарафыннан теркәлгән үрнәк форма буенча 2нче номерлы сырхауханә (консультатив-диагностика) бүлегенә юллама тутырыла. Табиблар-белгечләрнең кирәкле тикшеренүләре һәм консультацияләре ветеранның яшәү (ММИ полисын беркетү) урыны буенча медицина оешмаларында уздырыла.

3. Казан шәһ. Госпиталенең 2нче номерлы сырхауханә (консультатив-диагностика) бүлегенә җибәргәндә Казан шәһ. яшәүче ветераннар өчен юллама "Казан" литерасы белән кушылган үрнәк форма буенча тутырыла. Табиблар-белгечләрнең кирәкле тикшеренүләрен һәм консультацияләрен үткәрү Госпитальнең (Казан шәһ.) 2нче номерлы сырхауханә (консультатив-диагностика) бүлеге җирлегендә башкарыла.

4. Табиблар-белгечләргә консультатив кабул итүгә алдан язылып кую мөмкин: җибәрүче медицина оешмасы тарафыннан (юлламага тиешле билге ясала) яисә ветеран үзе тарафыннан түбәндәге телефон буенча: (843) 239-19-11 (күп каналлы).

Госпиталь (Казан шәһ.) регистратурасының эш графигы: атна саен дүшәмбе-җомга 7.30 башлап 19.30 кадәр.

5. Госпитальнең (Казан шәһ.) стационарларына ветераннарны госпитализацияләү медицина ярдәме төрләре буенча: «терапия», «кардиология», «неврология», «хирургия», «гериатрия», «ҮНС патология белән авыручыларны реабитацияләү бүлеге», «ПНС патологиясе белән авыручыларны реабилитацияләү

бүлеге», «эндокрин системасы патологиясе белән кардиологик авыручыларны соматик реабилитацияләү бүлеге» планлы билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

6. Госпитальгә (Казан шәһ.) стационар дәвалауга ветераннарны җибәрү Госпитальнең (Казан шәһ.) 2нче сырхауханә (консультатив-диагностик) бүлеге аша гамәлгә ашырыла, шул ук вакыта Госпиталь (Казан шәһ.) стационарына юллама кушылган үрнәк форма буенча рәсмиләштерелә.

7. Ветеранның планлы госпитализация өчен күрсәтмәләре, тикшеренүләр нәтиҗәләре, табиблар-белегчләрнең нәтиҗәләре, планлы госпитализацияләүгә чират (“көтү кәгазе”) булганда Госпитальнең (Казан шәһ.) табиб комиссиясе карары белә (профильле бүлек мөдире катнашуында) госпитализацияләүнең алдан куелган датасы билгеләнә, бу хакта юлламада тиешле билге ясала.

8. Ветеранны госпитальгә кадәр медицина тикшерүе мәҗбүри тәртиптә аның яшәү (ММИ полисын беркетү) урыны буенча медицина оешмаларында үткәрелә.

9. Госпитальдә (Казан шәһ.) ветераннарны планлы госпиталҗгә урнаштыру кабул итү бүлегендә (бүлмәсендә) Госпиталь (Казан шәһ.) стационарында атна саен 8.45 башлап 13.00 кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр гамәлгә ашырыла:

неврология бүлегенә - 9.30 башлап 10.30 кадәр;

медицина реабилитациясе бүлегенә:

ҮНС авырулары белән - 8.45 башлап 10.00 кадәр,

ПНС авырулары белән - 8.45 башлап 10.00 кадәр,

Соматик авырулар белән - 8.45 башлап 10.00 кадәр;

кардиология бүлегенә – 10.30 башлап 11.30 кадәр;

терапия бүлегенә (шул санда «гериатрия» профиле буенча) - 11.30 башлап 12.30 кадәр;

хирургия бүлегенә - 12.30 башлап 13.00 кадәр.

10. Ветераннарны ашыгыч һәм кичектергесез күрсәткечләр буенча госпитализацияләү авыруның профиле буенча медицина оешмаларына билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

11. Госпиталь (Казан шәһ.) урнашу урыны: 420039, Казан шәһ., Исаев ур., 5.

Телефоннары:

консультатив сырхауханәнең регистратурасы: (843) 239 19 11;

стационарның кабул итү бүлегенең: (843) 557 39 70.

Сайт: http://www.kazanhospital.ru

Электрон почта: gvv.kazan@tatar.ru

Казан шәһ.
«Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССУнә кабул итүгә һәм планлы стационар дәвалауга гражданнарның льготалы категорияләрен җибәрү вакытында медицина оешмаларының үзара хезмәттәшлек тәртибенә
Кушымта

Үрнәк форма

**Юллама**
сырхауханә (консультатив-диагностика)№2 бүлегенә
«Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» (Казан шәһ.)
420039, ТР, Казан шәһ., Исаев ур., 5,
регистратура тел.: (843)239-19-11

1. ____________________________________________
медицина оешмасының исеме
2. Табиб фамилиясе, исеме, атасының исеме
____________________________________________
3. Пациент фамилиясе, исеме, атасының исеме
____________________________________________
4. Яше ______ 5. Җенесе ______ 6. Пациент категориясе _________________
7. Җибәрү максаты (1 - белгечнең консультациясе (диагнозаны ачыклау), 2 – планлы стационар дәвалау, 3 - МСЭ алдында тикшерү, 4 – ИПРА буенча реабилитацион чаралар уздыру, 5 - тикшерү, 6 – башкалар (күрсәтергә) (кирәгенә астына сызарга)
____________________________________________
8. Юнәлеш диагнозы ______________________________
____________________________________________
9. амбулатор картадан кыска өземтә (авыруның анамнезы, соңгы стационар дәвалау, белгечләрнең алдагы консультацияләре, уздырылган дәвалауның нәтиҗәлелеге)
____________________________________________
10. Тикшеренүләрнең лаборатор һәм инструмент алымнары:
1 - ОАК ______________________________________
2 - ОАМ ______________________________________
3 - ЭКГ ______________________________________
4 - RW 65 яшькә кадәр_____________________________
5 - Гепатит В һәм С (яшенә карамыйча) ________________
6 - ВИЧ(50 яшькә кадәр пациентлар өчен, 50 олырак яшьтә - күрсәткечләр буенча) _
7 – Үпкә флюорографиясе (яисә Ro-графия)_______________
11. Башка тикшеренүләр
(күрсәтергә) __________________________________
____________________________________________

Дата ____________________________
Табиб имзасы ___________________ Җитәкче урынбасары
____________________________
Ф.И.О., имза
Билгеләнгән кабул итү датасы ____________ медицина оешмасының печате

Үрнәк форма

**«Казан»**

**Юллама**

сырхауанә(консультатив-диагностика)№ 2 бүлегенә
«Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССУ (Казан шәһ.)
420039, ТР, Казан шәһ., Исаев ур., 5,
регистратура тел: (843)239-19-11

1. ____________________________________________________________________
медицина оешмасы исеме
2. Табиб фамилиясе, исеме, атасының исеме
3. Пациент фамилиясе, исеме, атасының исеме
4. Яше ____ 5. Җенесе _________ 6. Пациент категориясе _________________
7. Җибәрү максаты (1 – белгечнең консультациясе (диагнозны ачыклау),
2 - планлы стационар дәвалау, 3 - МСЭ алдында тикшерү, 4 – ИПРА буенча реабилитацио чаралар уздыру, 5 - тикшерү,
6 – башкалар (күрсәтергә)(кирәгенә астына сызарга)
______________________________________________________________________
8. Юнәлеш диагнозы ____________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
9. Амбулатор картадан кыска өземтә (авыруның анамнезы, соңгы стационар дәвалау, белгечләрнең алдагы консультацияләре, уздырылган дәвалауның нәтиҗәлелеге)
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

Дата __________________________
Табиб имзасы _________________ Җитәкче урынбасары
____________________________
Ф.И.О., подпись
Билгеләнгән кабул итү датасы __________ медицина оешмасы печате

Үрнәк форма

| |
|---|
| **Стационарга юллама** |
| _____________________________бүлеге |
| «Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССУ Казан шәһ. |
| 420039, ТР, Казан шәһ., Исаев ур., 5, |
| Кабул иту бүлмәнең тел: (843)557-39-70 |
| |
| Сырхауханә (консультатив-диагностика) №2 бүлеге |
| «Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССУ Казан шәһ. |
| |
| 1. Табиб исем, фамилиясе, атасының исеме _____________________________ |
| 2. Пациент исем, фамилиясе, атасының исеме |
| 3. Яше __________ 4. Җенесе _________ 5. Пациент категориясе _____________ |
| 6. Юнәлеш максаты _________________________________________________________ |
| (1 - планлы стационар дәвалау, 2 - МСЭ алдында тикшерү, |
| 3.ИПРА буенча реабилитацио чаралар уздыру, 4. тикшерү |
| (диагноз ачыклау), 5. башкалар (күрсәтергә) (кирәгенә астына сызарга) |
| |
| |
| 7. Юнәлеш диагнозы: |
| ________________________________________________________________________ |
| ________________________________________________________________________ |
| 8. Лаборатор тикшеренүләр: |
| 1 - ОАК ___________________________________________________________ |
| 2 Кан гепатитларга___________________________________________________ |
| 2 - ОАМ ___________________________________________________________ |
| 3 - RW (65 яшькә кадәр)_____________________________________________________ |
| 4 - ВИЧ (50 яшькә кадәр пациентлар өчен), |
| 9. Инструмент тикшеренүләр: |
| 9.1. – ЭКГ тасвир белән__________________________________________________ |
| 10. Рентген тикшеренүләре ( үпкәләр флюорографиясе) ____________________ |
| 11. Белгечләр консультациясе, тикшеренүләрнең башка алымнары |
| 11.1 терапевт _____________________________________________________ |
| ________________________________________________________________________ |
| 11.2. невролог ____________________________________________________ |
| 11.3. хирург ______________________________________________________ |
| 11.4. башка белгечләр (офтальмолог, ЛОР, гинеколог, уролог) |
| ________________________________________________________________________ |
| ________________________________________________________________________ |
| ________________________________________________________________________ |
| Дата _____________________ Җитәкче урынбасары |
| _______________________________ |
| Табиб имзасы_______ Ф.И.О., имза |
| |
| Билгеләнгән кабул иту датасы ___________ медицина оешмасының печате |

2019 елның 12 февраленнән № 251
Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгына
№ 6 Кушымта
(Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгы
боерыгы редакциясендә
30.03.2020 № 566)

Яр Чаллы шәһ. “Сугышлар ветераннары өчен госпиталь” ДАССУдә планлы стационар дәвалауга льготалы категорияләр гражданнарын җибәргәндә медицина оешмаларының үзара эшчәнлек тәртибе

1. Яр Чаллы шәһ. “Сугышлар ветераннары өчен госпиталь” ДАССУдә (алга таба – Госпиталь (Яр Чаллы шәһ.) Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнарының льготалы категорияләренә (алга таба – ветераннар, ветеран) сырхауханә (амбулатор һәм консультатив) һәм тәүлек буе эшли торган стационар медицина ярдәме күрсәтелә.

2. Госпитальнең (Яр Чаллы шәһ.) стационарына ветераннарны госпитализацияләү медицина ярдәме төрләре буенча: «терапия», «кардиология», «гериатрия», «медицина реабитациясе» планлы тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Госпитальгә (Яр Чаллы шәһ.) стационарына ветераннарны җибәрү госпитальнең хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны реабилитацияләү бүлеге яисә яшәү урыны буенча (ММИ полисын беркетү урыны буенча) медицина оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла, шул ук вакытта Госпиталь (Яр Чаллы шәһ.) стационарына кушымта итеп бирелә торган үрнәк форма буенча (алга таба – Юллама) юллама рәсмиләштерелә.

4. Ветеранның планлы госпитализация өчен күрсәтмәләре, тикшеренүләр нәтиҗәләре, табиблар-белегечләрнең нәтиҗәләре, планлы госпитализацияләүгә чират (“көтү кәгазе”) булганда Госпитальнең (Яр Чаллы шәһ.) табиб комиссиясе карары белән (профильле бүлек мөдире катнашуында) госпитализацияләүнең алдан куелган датасы билгеләнә, бу хакта юлламада тиешле билге ясала.

5. Ветеранны госпитальгә кадәр медицина тикшерүе мәҗбүри тәртиптә аның яшәү (ММИ полисын беркетү) урыны буенча медицина оешмаларында яисә Яр Чаллы шәһ. госпитальнең хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны реабилитацияләү бүлеге үткәрелә.

6. Госпитальдә (Яр Чаллы шәһ.) ветераннарны планлы госпитальгә урнаштыру кабул итү бүлегендә (бүлмәсендә) Госпиталь (Яр Чаллы шәһ.) стационарында атна саен 09.30 башлап 11.30 кадәр дүшәмбедән җомгага кадәр гамәлгә ашырыла:

терапия бүлегенә (шул санда «гериатрия» профиле буенча) - 09.30 башлап 10.00 кадәр;

ҮНС авырулары белән - 10.15 башлап 10.45 кадәр,

ПНС авырулары белән - 10.45 башлап 11.30 кадәр

7. Ветераннарны ашыгыч һәм кичектергесез күрсәткечләр буенча госпитализацияләү авыруның профиле буенча медицина оешмаларына билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.

11. Госпиталь (Яр Чаллы шәһ.) урнашу урыны: 423802, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһ., Габдулла Тукай яр буе ур., 39.

Телефоннары:

кабул итү бүлегенең: (8552)79 30 03;

сырхауханәнең регистратурасы: (8552)79 30 36;

госпитальнең хәрби хәрәкәтләрендә катнашучыларны реабилитацияләү бүлеге (8552)79 30 31;

кайнар линия: (8552)79 30 33

стационар бүлекләрнең мөдирләре: терапия бүлегенең (8552)79 30 48; үзәк нерв системасы функцияләренең бозылуы белән пациентларны медицина реабитацияләү бүлекләре: (8552)79 30 49, периферик нерв системасы һәм терәк-хәрәкәт аппараты функцияләренең бозылуы белән пациентларны медицина реабитацияләү бүлекләре: (8552) 79 30 05.

Электрон почта: mz.nchelny_gvv@tatar.ru

Сайт: www.zdrav.tatar.ru/mz.nchelny_gvv

Яр Чаллы шәһ.
«Сугышлар ветераннары өчен госпиталь» ДАССУнә планлы стационар дәвалауга гражданнарның льготалы категорияләрен җибәрү вакытында медицина оешмаларының үзара хезмәттәшлек тәртибенә
Кушымта

Үрнәк форма

**Стационарга юллама**

___________________________бүлеге
Яр Чаллы «Сугышлар ветераннары өчен госпиталь»
423802, ТР, Яр Чаллы шәһ., Тукай яр буе ур., 39,
Кабул итү бүлегенең тел.: (8552)79-30-03

Медицина оешмасының исеме

1. Табиб фамилиясе, исеме, аның атасының исеме_____________
2. пациент фамилиясе, исеме, аның атасының исеме

3. Яше_______ 4. Җенесе __ 5. пациент категориясе __________________
6. Җибәренүнең максаты __________________________________________________
(1 - планлы стационар дәвалау, 2 - МСЭ алдында тикшеренү, 3. ИПРА буенча реабилитацион чаралар уздыру, 4. тикшерү (диагнозны ачыклау), 5. башкалар (күрсәтергә) (кирәгенә астына сызарга)
7. Юнәлеш диагнозы:
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________
8. Лаборатор тикшеренүләр:
1 - ОАК _______________________________________________________________
2 - ОАМ _______________________________________________________________
3 - RW ________________________________________________________________
4 - ВИЧ (50 яшьтә пациентлар өчен,50 яшьтән олырак күрсәткечләр буенча)
5 – гепатита В,С_ маркерлары ______________________________________________
9. Инструмент тикшеренүләр:
9.1 - ЭКГ тасвирлама белән_________________________________________________
10. Рентген тикшеренүләр (үпкәләр флюорографиясе) __________________
11. Белгечләр консультациясе, тикшеренүнең башка алымнары,
1. терапевт ____________________________________________________________
____________________________________________________________________________
2. невролог ____________________________________________________________
3. хирург ______________________________________________________________
4. башка белгечләр (офтальмолог, ЛОР, гинеколог, уролог)
____________________________________________________________________________
____________________________________________________________________________

Дата _____________________ Җитәкче урынбасары
____________________________________
Табиб имзасы ____________ Ф.И.О., имза

Билгеләнгән кабул итү датасы медицина оешмасы печате